Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Пимәр авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пимәр авыл җирлеге
Пимәр торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
**КАРАР**

16 октябрь, 2024 ел № 1

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пимәр авыл җирлегенең Пимәр торак пунктында 2024 елның 16 октябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 193 (йөз туксан өч).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 101 (йөз бер).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 101 (йөз бер).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 0 (ноль).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча

«Сез 2025 елда Пимәр авыл җирлеге Пимәр торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, биш һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләр, көндезге уку формасы студентлары, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары бер тапкыр бирелә торган түләүләрен (үзара салымын) түләүдән азат ителүе белән яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү;
- торак пункт территориясен төзекләндерү» **кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Пимәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Пимәр авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Гыйматдинов